

Тимер юл – хокvмәтнен ин кирәкле транспорт системасы. Ул зур шәһәр-ләрне, кешеләр яшәгән урыннарны тоташтыра, торле илләр белән элемтә тотарга булыша. Юлчыларга комфорт белән бергә, хужалыкларнын vсешенә зур олеш кертә. Бу система әйбәт эшләсен дисәгез, бик кvп халыкнын кочен кулланырга кирәк. Машинистлар, инженерлар, ремонтлау буенча мастерлар, проводниклар, вокзал хезмәткәрләре һәм башка бик кvпләр быел да лаеклы рәвештә профессиональ бәйрәмнәрен августнын беренче ял конендә билгеләп vттеләр. Мордовиядә Рузаевка гасырдан артык корыч магистраль шәһәре дип санала. Тагы аны республикабызнын тимер кабаклары дип тә йортәләр. Рузаевка шәһәренен һәм районынын 25% кешесе тимер юлда эшли. Берничә буын илебезнен торле почмакларына товарларны һәм халыкны исән-имин житкерv буенча тимер юл предприятияләрендә хезмәт иткән һәм итә.

«Ел саен производство vсешен арттыра барабыз, бездә тимер юл буенча кvчерv vскәннән-vсә, эш урыннары арта, - ди эксплуатация буенча локомотив депосы житәкчесе урынбасары В.В.Долгов. - Мәсәлән, vткән елга караганда 17%лы vсеш белән эшлибез, шуна тәнгәл йок һәм пассажирларны кvчерv дә арта. Техникабызны да янартып киләбез; яна тор локомотивлар (2ЭС6 грузлы режимда һәм ЭП2К – пассажир юнәлешендә) vзләштерәбез. Бик тә унган хезмәткәрләр буларак бригада составындагы хезмәт итvче электровоз машинисты Ринат Саяр улы Чалдаев белән машинист ярдәмчесе Олег Владимирович Стрижевны әйтергә була. Кыскасы, юлларыбыз корычтан, ә халкыбыз алтыннан».

Ринат Саяр улы 1984 елдан алып тимер юлда хезмәт итә. Хезмәтләрендә булган баскычларнын барысын да vткән: машинист ярдәмчесеннән алып беренче класслы машинистка кадәр vскән. Ин әйбәт наставникларнын берсе. Чалдаев машинист беренче буларак яна серия локомотивларны йорткән һәм бvген дә яшьләрне шуна ойрәтә. Ни очен бу авыр профессияне сайладын дигәч, Ринат Саяр улынын абыйсы гомере буе машинист булып эшләгән һәм ул vзе дә тимер юл янында яшәгән, ди. Ринат Чалдаев: «Мин тимер юл янында урнашкан Татар Пешләсе авылында тудым. Мина һәрвакыт чыжлап vтеп барган поездлар ошый иде. Балачактан ук тимерюл училищесына укырга баруымны һәм тимер юлда эшлиячәгемне белдем. Хыялым тормышка ашты. Торлесе булды инде эш дәверендә. Бигрәк истәлекле булды беренче тапкыр юлга чыгуым. Беркайчан исемнән чыкмый. Геннадий Бабакаев машинист иде, ә мин янында – дублер. Юлга кондез чыктык. Пешләбез яныннан vткәндә, юл кырыена баскан әнием мине кул

болгап озатты. Шул вакыт әниемнен йозендә чиксез шатлык чаткылырын кvреп алдым».
Тимер юлда Ринат Саяр улы Чалдаев 33 ел эшли инде. Бу вакыт эчендә торлесен кvрергә туры килгән vзенә, чиктән тыш хәлләр дә булган. Ике ел элек Мәскәv юлында шундый котелмәгән хәл килеп чыккан:  Самара – Москва поезды, Мәскәvдән 132 километр читтә барганда, составнын автосцепкасы бер жирдән озелә һәм нәтижәдә вагоннар бер-берсеннән ике якка таба китә. Шул минутларны искә алган машинист: «Беренче минутта аяк-кулларым, буыннарым калтыравын сиздем, чонки вагоннарым мәтәлеп китте дип уйладым. Бу бик тә куркыныч булды, чонки мин ничә йоз кеше гомере очен жаваплы бит! Инструкциядә кушылганча, шул вакыт тиз генә поездны туктаттым. Ярый әле ундvрт вагоннын алтысы озелгән. Шул вакыт аз вагон озелгән булса иде, туктату (тормозной) эффекты житмәс иде һәм составнын озелгән ике ягы бер-берсенә бәрелгән булыр иде. Менә шунда булган булыр иде хәлләр! Бәхеткә каршы, озелгән алты вагон 50 метр гына ерак-лыкта туктады, топ составка бәрелмәде. Бу очракны vлгәнче онытмам».
Хезмәттәшләре белән уртак тел табып эшли машинист Чалдаев. Пассажирлар колоннасы тату коллективын Ринат Саяр улы бик тә хормәт итә. Ул алтын куллы, корыч йорәкле хезмәттәшләренен һәм хормәтле наставникларынын һәр-вакыт ярдәмгә киләләчәкләрен белә, щуна эшләре алга киткән. Бvген vзенен ярдәмчесе Олег Владимирович Стрижев белән, пассажир составларын Рузаевка-Мәскәv һәм Рузаевка-Сызрань тимерюлларында йортә. Футбол Чемпионаты vткән вакытта пассажирлар кvпкә vскән һәм аларнын эше дә кvпкә арткан, шуна хезмәт графиклары бик тә тыгыз булган. Чемпионат vткән вакытны искә алып Ринат Саяр улы болай ди: «Поездлар бик кvп булды, эшебез чиксез тыгыз иде, әмма коллективыбыз бу олы бурычны да тырышып vтәде. Булган пассажирларны ойләренә кайтарып куйдык, якташларыбыз белән чит ил кунаклары бернинди канәгатьсезлек белдермәде».
Профессиональ бәйрәм унаеннан Рузаевка локомотив - эксплуатацион депо профкомы рәисе В.А.Филимонов предприятиянен унышларын билгеләп: «Увеличилась тонно-километровая работа, соответственно возросла заработная плата и сейчас мы занимаемся приемом молодых работников – помощников машиниста. Хочу сказать, что локомотивное депо в этом году работает стабильно и выполняет все технико-экономические показатели. Особенно много работы было в связи с проведением ЧМ по футболу в городе Саранск. Наша Рузаевка тоже значительно преобразилась – изменился в лучшую сторону вокзал, построен красавец пешеходный переход. Все задания по перевозкам болельщиков в Саранск, Москву и Самару работники локомотивного депо выполнили, в движении составов не было ни одного сбоя. Здесь можно отметить как пассажирскую колонну, так и другие бригады, которые занимались ремонтом путей. Их работу не видно, но они сделали все, что от них зависело. В канун этого знаменательного праздника хотелось бы поздравить ветеранов отрасли, которые работали и заложили фундамент того, что сейчас есть. Рузаевка – это город железнодорожников и в каждой семье кто-то работает в этой сфере. Хочу пожелать им здоровья, а также, чтобы всегда была работа и достойная зарплата».

**Н.Хәлил**, *фото «Рузаевка яналыклары» газетасыннан алынды*